КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 декабрь г.Казань № 1136

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 август, 673 нче карары белән расланган 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 19 август, 673 нче карары белән расланган 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре,

Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктның икенче абзацында «2024 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «2025 елның 31 августыннан да соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга.

17 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотуга ихтыяҗ булган очракта, муниципаль район Министрлыкка 2025 елның беренче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, муниципаль районнан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин